ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«06» май 2022 ел № 62-р

Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 77 еллыгына багышланган ирләр командалары арасында футбол буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы турнирын үткәрү турында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында футболны популярлаштыру һәм үстерү, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, ярышларда катнашучыларның спорт осталыгын арттыру максатларында:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль үсеш бүлегенә 2022 елның 9 маенда Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 77 еллыгына багышланган ирләр командалары арасында футбол буенча ТР Әгерҗе муниципаль районы турнирын оештырырга һәм уздырырга.

2.Кушымта итеп бирелгәннәрне расларга:

- Ирләр командалары арасында Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 77 еллыгына багышланган футбол буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы турнирын уздыру турында нигезләмә
- турнир уздыруга чыгымнар сметасы.

3. «Татмедиа» АҖ филиалы Әгерҗе районының «Әгерҗе хәбәрләре» редакциясенә, «Әгерҗе радиосына» 2022 елның 9 маенда ирләр командалары арасында Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 77 еллыгына багышланган футбол буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы турнирын массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге күрсәтмәне Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru.

5. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Баженовага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Башкарма
комитетының 06.05.2022 № 62-р
карары белән расланган

# Ирләр командалары арасында Бөек Ватан сугышында Җинүнен 77 еллыгына багышланган футбол буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы турнирын уздыру турында нигезләмә

**1. Максатлар һәм бурычлар**

- футболны популярлаштыру һәм үстерү;
- яшьләрне патриотик тәрбияләү;
- халыкны физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү;
- ин көчле спортчылар һәм командаларнын барлыкка килүе;
- җиңүчене һәм призерларны билгеләү.

**2. Үткәрү вакыты һәм урыны**

Ярышлар 2022 елнын 09 маенда стадионда ТР, Әгерҗе шәһәре, Пушкин урамы 4 адресы буенча уздырыла. 12.30 сәгатьтә стадионда судьялар коллегиясе киңәшмәсе
Ярышлар 13.00 сәгатьтә 18.00 сәгатькә кадәр.

**3. Ярышларны уздыру белән җитәкчелек итү**

Ярышларның гомуми җитәкчелеген Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районынын «Спорт мәктәбе» МБУ башкара. Ярышларны турыдан-туры уздыру баш судья - Колчина Алексей Владимировичка, социаль үсеш бүлеге баш белгече Жуйков Тимур Владленовичка йөкләнә.

**4. Ярышларда катнашучылар**

Турнирда катнашырга теләүче барлык командалар да катнаша ала.

**5. Уздыру шартлары:**

Турнир футболның гадиләштерелгән кагыйдәләре буенча 30 минутлык ике таймда уздырыла. Команда составы - 14 кеше, кырда 10 уенчы 1 капкачы уйный, алыштыру һәм кире алыштыру рөхсәт ителә. Командаларнын очколары тигез булганда:
-өстәмә вакыт (2х10 мин) билгеләнә.
- пенальти билгеләнә.

**6. Бүләкләү**

1, 2, 3 урыннарны алган командалар грамоталар һәм медальләр, 1 урын өчен Кубок белән бүләкләнә.

**7. Финансирование**

Ярышларны әзерләүгә һәм уздыруга, җиңүчеләрне һәм призерларны бүләкләүгә бәйле барлык чыгымнарны - кызыксынучы оешмалар һәм затлар күтәрә.

Командаларны туплау чыгымнарын командалар үзе күтәрә. Ярышларны оештыру чыгымнарын Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районынын «Спорт мәктәбе» МБУ каплый.

**8. Гаризалар**

Учреждение җитәкчесе һәм табиб тарафыннан расланган гаризалар ярышлар көнендә төп судья коллегиясенә тапшырыла. Ярышлар алдыннан командалар вәкилләренә ярышларда катнашучылар арасында куркынычсызлык техникасы буенча инструктаж үткәрергә. Ярышта катнашучыларга уеннарга 20 минут кала килергә кирәк.

**Контакт телефон: 89600804920, 89635465797**

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Башкарма
комитетының 06.05.2022 № 62-р
карары белән расланган

Ирләр командалары арасында Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 77 еллыгына багышланган футбол буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы турнирын уздыруга чыгымнар сметасы

| № | Товарлар | Саны | Бер штук өчен бәясе, сум | Бәясе, руб. |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Грамоталар «Хакер» | 10 | 20-00 | 200-00 |
| 2 | Медальләр | 40 | 100-00 | 4000-00 |
| 3 | Кубоклар | 1 | 900 | 900-00 |
| | **Барлыгы:** | | | **5100-00** |